**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станция Высокая Гора,
Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЕ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Кооперативная ур., 5, Биектау т/ю станциясе поселогы,
Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-50, факс: 2-30-86, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**
**от 06.07.20223** **№885**

## Җир кишәрлегеннән файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү мәсьәләсе буенча фикер алышу өчен гавами тыңлаулар билгеләү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 37, 39 статьяларына, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Уставына таянып, халыкның фикер алышуда катнашу хокукларын үтәү максатларында, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. 2023 елның 28 июленә 14 сәгать 00 минутка, җир кишәрлегеннән файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә - Хәкимов Азат Фанисович милкендәге 864 квадрат метр мәйданлы 16:16:190803:2245 кадастр номерлы җир кишәрлегенә «торак төзелешенә хезмәт күрсәтү» (код 2.7) рөхсәт ителгән файдалану төренә рөхсәт бирү мәсьәләсе буенча фикер алышу өчен гавами тыңлаулар уздыруны түбәндәге адрес буенча: Татарстан Республикасы, Биектау районы, Биектау ав., Юбилей ур., 1а й., Биектау авыл җирлеге администрациясе бинасында билгеләргә.

2. Кызыксынучы затка «Биектау хәбәрләре» газетасында җир кишәрлегеннән файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү мәсьәләсе буенча фикер алышу өчен гавами тыңлаулар үткәрелү урыны һәм вакыты турында мәгълүматны бастырып чыгару белән бәйле чыгымнарны Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 39 статьясының 10 пункты нигезендә үз өстенә алырга.

3. Гавами тыңлауларда каралырга тиешле мәсьәлә буенча тәкъдимнәр һәм искәрмәләрне кабул итүне Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты бинасында, Татарстан Республикасы, Биектау муниципаль районы, Биектау т/юл. станциясе п., Кооператив ур., 5 йорт, 105 каб. адресы буенча эш көннәрендә көн саен 08.00 сәгатьтән 17.00 сәгатькә кадәр 2023 елның 07 июленнән 2023 елның 27 июленә кадәр чорда һәм шулай ук 2023 елның 28 июлендә турыдан-туры гавами тыңлаулар уздырганда гамәлгә ашырырга.

4. Җир кишәрлекләреннән рөхсәт ителгән файдалануның бер төрен мондый файдалануның башка төренә үзгәртү мәсьәләсе буенча гавами тыңлаулар уздыру буенча түбәндәге составта эшче төркем төзергә:

1) Хәбибуллин А.А. - Биектау авыл җирлеге башлыгы – Рәислек итүче;

2) Арсланова В.Н. - Биектау авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары - Секретарь;

3) Дамоцев И.С. – Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык бүлеге баш белгече;

4) Хидиятуллин М.Ф. - Биектау авыл җирлеге депутаты;

5) Садреев З.З. - Биектау авыл җирлеге депутаты.

5. Эш төркеменә катнаш кишәрлекләр милекчеләренә хәбәр итәргә (Форма кушымтада бирелә).

6. Эш төркеменә Биектау муниципаль районы территориясендә җирдән файдалану һәм төзелеш комиссиясенә гавами тыңлаулар нәтиҗәләре буенча беркетмә һәм бәяләмә әзерләп җибәрергә.

7. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда: http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

8. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының «Җир кишәрлегеннән файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү мәсьәләсен карау өчен гавами тыңлаулар билгеләү турында» 2023 елның 23 июнендәге 813 номерлы карарын гамәлдән чыгарырга.

9. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны район Башкарма комитеты җитәкчесенең төзелеш, архитектура һәм ТКХ буенча урынбасары Р.Ф. Хәкимуллинга йөкләргә.

Биектау муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе Д.Ф. Шәйдуллин